**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«07» 02 2025 ел Яр Чаллы №179

2025-2027 елларга Тукай муниципаль районында дәүләт яшьләр сәясәтен үстерү стратегиясен раслау турында

Тукай муниципаль районында яшь буын кеше капиталын саклап калуга, формалаштыруга һәм туплауга юнәлтелгән яшьләр сәясәтенең инновацион моделен булдыру максатында, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2025-2027 елларга Тукай муниципаль районында дәүләт яшьләр сәясәтен үстерү стратегиясен (алга таба – Стратегия) расларга.
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контольдә тотуны Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ю.П. Васильевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның «07» 02 179 номерлы карары белән расланган

# 2025-2027 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында дәүләт яшьләр сәясәтен үстерү стратегиясе

Яр Чаллы шәһәре
2025 ел

**Стратегия паспорты**

| | |
|---|---|
| Стратегия исеме | 2025-2027 елларга Тукай муниципаль районында дәүләт яшьләр сәясәтен үстерү стратегиясе |
| Стратегияне эшләү өчен нигез | - Татарстан Республикасының 2023 елга кадәр дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясе, 04.02.2016 ел, № 63<br>- «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасы, 05.03.2019 ел, № 158<br>- «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы законы |
| Заказчы | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Эшләүче | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| Башкаручылар | - Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге:<br>- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мәгариф идарәсе» МКУ;<br>- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге;<br>- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының ГХАТ бүлеге;<br>- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Тукай муниципаль районында социаль яклау бүлеге |
| Стратегиянең максаты | Яшьләрнең социаль һәм икътисадый активлыгын күтәрү, үзеңне реализаөияләү өчен хокукый, икътисадый һәм оештыру шартлары һәм гарантияләр булдыру, яшь кешене һәм яшьләр берләшмәләрен Тукай муниципаль районының иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышына җәлеп итү |
| Стратегиянең бурычлары | 1. Социаль-икътисадый, иҗтимагый-сәяси, мәдәни-иҗат, спорт, мәгълүмати һәм эшчәнлекнең башка өлкәләрендә яшьләрнең потенциалын һәрьяклап гамәлгә ашыру һәм актив файдалану өчен шартлар тудыру.<br>2. Яшьләр мохитендә гражданлык-патриотик тәрбия, милли үзаң һәм толерантлык системасын үстерү.<br>3. Ящьләрнең ирекле ярдәмчеләр эшчәнлегенә катнашуы, ирекле ярдәмчелекнең оешкан формаларына ярдәм итү өчен шартлар тудыру.<br>4. Яшьләр иҗтимагый оешмалары, хәрәкәтләре өчен шартлар тудыру, яшьләрнең лидерлык сыйфатларын үстерү һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары инициативасы белән оештырылган социаль әһәмияткә ия проектларга ярдәм итү өчен шартлар тудыру.<br>5. Сәләтле балаларны һәм яшьләрне эзләү, аларга ярдәм итү, аларның интеллектуаль һәм иҗади потенциалын үстерү һәм гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру.<br>6. Яшьләр мохитендә социаль-тискәре күренешләрне профилактикалауның нәтиҗәле системасын формалаштыру һәм гамәлгә ашыру.<br>7. Яшьләр арасында экстремизмны профилактикалау.<br>8. Гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру, аерылышулар санын киметү, демографик хәлне яхшырту |

| | |
|---|---|
| Стратегияне гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2025-2027 еллар |
| Стратегия максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре | - Оешкан процессларга җәлеп ителгән яшьләр өлешен 50%ка кадәр арттыру, яшь кешене һәм яшьләр берләшмәләрен Тукай муниципаль районының социаль-икътисадый, иҗтимагый-сәяси һәм социаль-мәдәни тормышына тарту;<br>- муниципаль идарәнең кадрлар резервын формалаштыру максатында, иҗтимагый тормышның төрле өлкәләрендә социаль-актив яшьләрне ачыклау;<br>- яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең социаль әһәмиятле программаларында һәм проектларында эшләүче яшьләр санын арттыру;<br>- яшьләрдә патриотик, хезмәт, эшмәкәрлек, иҗади, сәяси һәм гражданлык активлыгы дәрәҗәсен күтәрү;<br>- сәламәт яшәү рәвешенә, аралашу даирәсен сәламәтләндерүгә һәм яхшыртуга тарту |

## 1. Төп нигезләмәләр

Яшьләр – җәмгыятьнең иң актив өлеше, бу социаль төркемгә карата эзлекле максатчан сәясәт алып баруның мөһимлеген билгели. Яшь буынның потенциалына икътисад-технология, фән, социаль һәм мәгълүмат өлкәләрендә ихтыяҗ зур. Яшьләрнең социаль аякка басуы һәм үсеше, аның мөмкинлекләрен һәр яшь кеше һәм бөтен җәмгыять мәнфәгатьләрендә тулырак тормышка ашыру Стратегияне гамәлгә ашыруның максатларын, бурычларын, өстенлекле юнәлешләрен һәм механизмнарын перспективалы күзаллау ихтыяҗын актуальләштерә.

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясе (алга таба – Стратегия) 2027 елга кадәр чорга эшләнде һәм Тукай муниципаль районы территориясендә дәүләт һәм иҗтимагый яшьләр сәясәтенең эчтәлекле нигезләрен, үзара хезмәттәшлек механизмын һәм яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыру системасын билгели.

Хәзерге этапта яшьләр сәясәте өлкәсе социаль, икътисадый, сәяси мәсьәләләр, демография, гаилә һәм торак сәясәте, мәгариф, тәрбия, фән, спорт һәм психология проблемаларын үз эченә ала. Аларны нәтиҗәле хәл итү кеше капиталына һәм, барыннан да элек, яшьләргә инвестицияләр кертмичә мөмкин түгел.

Яшь буынның төп сәяси үсеш процессларына, демократик институтларның ныклыгын ныгытуга, икътисадый үсешне тизләтүгә, инновацион технологияләр кертүгә, социаль әһәмияткә ия инициативаларны гамәлгә ашыруга максималь рәвештә кушылуы мөһим.

Район яшьләренең нәтиҗәлелеген югары заманча стандартлар нигезендә инновацион яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру шартында гына тәэмин итәргә мөмкин. Күрсәтелгән модельгә күчү процессын активлаштыруның төп механизмы Тукай муниципаль районы дәүләт яшьләр сәясәтенең әлеге стратегиясе булырга тиеш.

Стратегиянең актуальлеге бүгенге яшьләр сәясәтенең нәтиҗәлелеген билгеләүче берничә факторның булуы белән аңлатыла, алар арасында:

- яшьләрнең барлык категорияләренә һәм мөһим социаль институт буларак яшьләр сәясәте өлкәсенә таләпләрнең арта баруы, ул торган саен нәтиҗәлерәк булырга тиеш;
- заманча шартларда яшьләр арасында динамик рәвештә үзгәрүче социомәдәни мохитнең катлаулылыгы һәм каршылыклылыгы, аның үзенчәлекләре һәм үсеш тенденцияләре;
- заманның яңа глобаль таләпләре, дөнья процесслары динамикасы нигезендә яшьләр сәясәте өлкәсен камилләштерүнең объектив ихтыяҗы;
- булган кадрлар, инновация, инфраструктура потенциалыннан һәм республиканың уңай тәҗрибәсеннән оптималь файдалану, шулай ук республиканың икътисадый, социомәдәни

тормышының яшьләрнең практик проблемаларын хәл итү өчен үз өстенә җаваплылык алучы төрле субъектлары интеграциясе нәтиҗәсендә ачылучы яшьләр сәясәте өлкәсен үстерүнең яңа мөмкинлекләре;

- яшьләр сәясәте өлкәсендәге бурычларны хәл итүдә иҗтимагый институтларның һәм бизнес-бергәлекләрнең катнашуын көчәйтү зарурлыгы.

## 2. Җирле үзенчәлекләргә характеристика

Дәүләт статистикасы федераль хезмәте мәгълүматлары буенча Тукай районында халык саны 51140 кеше тәшкил итә, 11056 кеше – 14 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшьләр, бу гомуми халыкның 21%ын тәшкил итә. Еш кына бу төркем эчендә яшүсмерләр кластерын (14-17 яшь); яшьләр кластерын (18-24 яшь), иртә өлкәнлек кластерын (25-30 яшь) аералар. Шулай ук яшьләрне укучыларга (мәктәп укучыларына), эшләүче яшьләргә һәм яшь гаиләләргә бүлү дә гомум кабул ителгән.

Тукай муниципаль районында исәпләнә:

- 22 гомуми белем бирү учреждениесе,
- 182 спорт корылмасы,
- 1 спорт мәктәбе;
- 30 китапханә;
- 2 музей;
- 1 сәнгать мәктәбе;
- 42 мәдәният йорты.

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге «Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» МБУ, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы яшьләр үзәге» МБУ, «Балкыш» балалар сәламәтләндерү лагере кебек яшьләр өлкәсе учреждениеләре эшчәнлеген координацияли.

Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге «Мәгариф идарәсе» МКУ, мәдәният бүлеге, социаль яклау бүлеге, хәрби комиссариат, сәламәтлек саклау, «Беренчеләр хәрәкәте» төбәк бүлеге, «ЮНАРМИЯ» бөтенроссия балалар-яшүсмерләр хәрби-патриотик иҗтимагый хәрәкәте, район Советы каршындагы Яшьләр парламенты, «Бердәм Россия Яшь Гвардиясе» яшьләр иҗтимагый бүлекчәсенең җирле бүлеге, ирекле ярдмчеләр хәрәкәте, «Татарстан – Яңа гасыр» төбәк иҗтимагый хәрәкәтенең җирле бүлеге һ.б. кебек балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек итә.

Булган ресурслар: максатчан программалар, норматив-хокукый база, партнерлар, алга киткән учреждениеләр челтәре.

Ресурслар кытлыгы: яшьләр сәясәте учреждениеләрендә штаттагы хезмәткәрләр саны.

## 3. Стратегиянең төп максатлары һәм бурычлары

**Максат:**

Яшьләрнең социаль һәм икътисадый активлыгын күтәрү, үзеңне реализацияләү өчен хокукый, икътисадый һәм оештыру шартлары һәм гарантияләр булдыру, яшь кешене һәм яшьләр берләшмәләрен Тукай муниципаль районының иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышына җәлеп итү.

**Бурычлар:**

1. Социаль-икътисадый, иҗтимагый-сәяси, мәдәни-иҗат, спорт, мәгълүмати һәм эшчәнлекнең башка өлкәләрендә яшьләрнең потенциалын һәрьяклап гамәлгә ашыру һәм актив файдалану өчен шартлар тудыру.
2. Яшьләр мохитендә гражданлык-патриотик тәрбия, милли үзаң һәм толерантлык системасын үстерү.
3. Яшьләрнең ирекле ярдәмчеләр эшчәнлегенә катнашуы, ирекле ярдәмчелекнең оешкан формаларына ярдәм итү өчен шартлар тудыру.

4. Яшьләр иҗтимагый оешмалары, хәрәкәтләре өчен шартлар тудыру, яшьләрнең лидерлык сыйфатларын үстерү һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары инициативасы белән оештырылган социаль әһәмияткә ия проектларга ярдәм итү өчен шартлар тудыру.
5. Сәләтле балаларны һәм яшьләрне эзләү, аларга ярдәм итү, аларның интеллектуаль һәм иҗади потенциалын үстерү һәм гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру.
6. Яшьләр мохитендә социаль-тискәре күренешләрне профилактикалауның нәтиҗәле системасын формалаштыру һәм гамәлгә ашыру.
7. Яшьләр арасында экстремизмны профилактикалау.
8. Гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру, аерылышулар санын киметү, демографик хәлне яхшырту.

## 4. Төп проблемалар

Яшүсмерләр арасында:
- тәрбия;
- интернетның аңга тискәре йогынтысы;
- социаль челтәрләрдә үз-үзеңне тоту культурасының түбән дәрәҗәсе.

Эшче яшьләр арасында:
- чараларда катнашуның пассивлыгы һәм катнашуның түбән булуы;
- авыл торак пунктларында һәм предприятиеләрендә лидерлар булмау;
- торак пунктларда яшьләр белән эшләү учреждениеләренең җитәрлек дәрәҗәдә үсеш алган инфраструктурасы булмау.

Яшь гаиләләр арасында:
- авыл җирендә яшь гаиләләрнең ялын үткәрү өчен урыннар, киңлекләр җитмәү;
- торак;
- эшкә урнашу;
- аерылышуларның югары күрсәткечләре.

## 5. Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләре

1. Яшьләрнең иҗтимагый әһәмиятле инициативаларына ярдәм итү һәм талантлы яшьләрне үстерү: иҗади һәм фәнни потенциалны ачуга ярдәм итү, яшьләрне техник иҗатка, уйлап табучанлыкка һәм инновацион эшчәнлеккә кызыксындыруны тәэмин итү; фән өлкәсендә яшь белгечләрнең эшчәнлегенә ярдәм итү; яшьләрнең иҗади потенциалын үстерү; районны үстерүгә юнәлтелгән яшьләр инициативаларына ярдәм итү;
2. Яшьләрнең белем үсеше векторын төзүдә өлкән мәктәп яшендәге яшьләрнең һөнәри ориентациясен оештыру: укучылар арасында яшь кешенең булачак һөнәрне аңлы рәвештә сайлавына юнәлтелгән һөнәри юнәлеш бирү эшен көчәйтү; заманча җәмгыять үсеше тенденцияләрен исәпкә алып, яшьләргә һөнәри юнәлеш бирү программаларын әзерләүнең һәм гамәлгә ашыруның яңа методикаларын эшләү;
3. Яшьләрне эшкә урнаштыру: каникул чорында эшкә урнаштыру максатларында, 14-16 яшьлек яшьләргә мәгълүмати һәм ресурс ярдәме күрсәтү; икътисадый ихтыяҗ шартларында яшьләрнең хезмәткә җайлашуына ярдәм күрсәтү;
4. Сәламәт яшәү рәвеше кыйммәтләрен формалаштыру, наркотиклардан, алкогольдән һәм тәмәкедән башка яшәү культурасын күтәрү өчен шартлар тудыру: яшьләрнең төрле төркемнәрендә шәхес формалашуның яшь, психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып, шул исәптән мәгълүмат бирүнең заманча ысулларын кулланып, яшьләрдә сәламәт яшәү рәвешенә (сәламәт туклану, спорт белән шөгыльләнү, тәмәке тартудан, наркотиклардан, алкогольдән баш тарту) уңай мөнәсәбәт формалаштыру; наркотиклар, алкоголь, психотроп чаралар куллануны, тәмәке тартуны профилактикалау;
5. Яшьләр мохитендә хокук бозуларны профилактикалау: балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау өлкәсендәге эшчәнлекне оештыру-

методик тәэмин итү һәм координацияләү; авыр тормыш хәлендә калган яшьләрне социализацияләү;

6. Яшьләргә гражданлык-патриотик һәм рухи-әхлакый тәрбия бирү системасын үстерү, районның тарихи-мәдәни мирасын яшьләр тирәлегенә трансляцияләү: гражданлык һәм патриотик тәрбия системасын үстерүдә яңа формалар һәм алымнар кертү; яшьләрдә Россия Федерациясенең хокукый һәм дәүләт системаларына, Ватан тарихына һәм дәүләт символикасына уңай мөнәсәбәт формалаштыруга ярдәм итү; яшьләр арасында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт итүне, Ватанны саклаучылар истәлеген мәңгеләштерү эшләрен популярлаштыру, сугыш һәм хезмәт ветераннары оешмаларының яшьләр белән үзара хезмәттәшлеге, яшьләрне эзләү отрядлары һәм хәрби-патриотик клублар эшчәнлегенә җәлеп итү; гражданлык һәм патриотизм формалаштыруга юнәлтелгән социаль әһәмиятле яшьләр проектларын һәм программаларын эшләтүгә ярдәм итү;

7. Яшь гаиләләрнең социаль-икътисадый проблемаларын хәл итүдә ярдәм итү һәм яшьләр мохитендә гаилә культурасы кыйммәтләрен формалаштыру: яшьләр арасында тормыш өстенлекләре буларак гаиләгә һәм теркәлгән никахка, гаилә кыйммәтләренә карата уңай мөнәсәбәт формалаштыру, уңышлы яшь гаилә образын алга сөрү, гаилә мөнәсәбәтләре культурасын трансляцияләү; яшь гаиләләрнең инициативаларына һәрьяклап ярдәм күрсәтү; традицион гаилә кыйммәтләрен, уңай яшь гаилә образын, гаиләдә балалар туу һәм тәрбияләүне пропагандалау; социаль-икътисадый проблемаларны хәл итүдә яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтү;

8. Балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә ярдәм итү һәм районда дәүләт яшьләр сәясәте юнәлешләре буенча эшчәнлек алып баручы оешмалар белән үзара хезмәттәшлек итү;

9. Яшьләр медиа пространствосын үстерү: яшьләр мәгълүмат пространствосы өлкәсендә яшьләр инициативаларының инновацион формаларын һәм методларын кертү; массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәрендә яшьләр проектларына мәгълүмати ярдәм күрсәтүне тәэмин итү; яшьләрне җирле һәм төбәк массакүләм мәгълүмат чаралары эшенә җәлеп итүдә ярдәм күрсәтү.

## 6. Стратегияне гамәлгә ашыру юллары

- Тукай муниципаль районында яшьләр берләшмәләренә ярдәм итү буенча норматив-хокукый база эшләү;
- яңа эш формаларын кертү;
- яшьләрнең республика һәм төбәк конкурсларында катнашуы;
- яшьләрдә патриотик, хезмәт, эшмәкәрлек, иҗади, сәяси һәм гражданлык активлыгы дәрәҗәсен күтәрү;
- яшьләрнең районның социаль-икътисадый, иҗтимагый-сәяси һәм социомәдәни тормышына кушылу;
- яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең социаль әһәмиятле программаларында һәм проектларында эшләүче яшьләр санын арттыру;
- иҗтимагый тормышның төрле өлкәләрендә социаль актив кешеләрне ачыклау;
- массакүләм мәгълүмат чараларында, социаль челтәрләрдә яшьләр сәясәте турында мәгълүмати материаллар санын арттыру.

Стратегия бурычларын хәл итү чараларының нәтиҗәлелеге фестивальләр, конкурслар, олимпиадаларга җәлеп ителгән балалар һәм яшьләрнең чагыштырма зурлык күрсәткечләре һәм иҗтимагый яшьләр оешмаларына җәлеп ителгән яшьләрнең чагыштырма зурлык күрсәткечләре, шулай ук яшьләр инфраструктурасының үсеше һәм тотрыклы эшләве нигезендә бәяләнәчәк.

**2025-2027 елларга Тукай муниципаль районында дәүләт яшьләр сәясәтен үстерү стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планы («юл картасы»)**

| № | Чара | Башкару сроклары | Көтелгән нәтиҗә |
|---|---|---|---|
| 1 | Яшүсмерләр клубы һәм яшьләр үзәге эшчәнлеген тәэмин итү | 2025 – 2027 | Тукай муниципаль районында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру |
| 2 | Яшьләрне ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеге өлкәсенә җәлеп итү һәм чаралар үткәрү | 2025 – 2027 | Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлегенә җәлеп ителгән яшьләр өлеше, ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеген үстерү өлкәсендәге чараларга җәлеп ителгән кешеләр саны |
| 3 | Яшь гаиләне ныгытуга ярдәм итү, алар катнашында мәдәни-ял һәм спорт чаралары уздыру | 2025 – 2027 | Уңай социаль потенциаллы имин яшь гаиләләр санын арттыру, гаилә институтының абруен күтәрү |
| 4 | Яшьләрнең гражданлык формалашуы, патриотик, рухи-әхлакый тәрбиясе өчен шартлар тудыру | 2025 – 2027 | Яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү, милли горурлык, тарихи хәтер тәрбияләү |
| 5 | Яшьләрнең инновацион эшчәнлегенә ярдәм итү, талантлы һәм сәләтле яшьләргә үзләрен реализацияләү өчен шартлар тудыру | 2025 – 2027 | Иҗтимагый оешмалар проектларына һәм программаларына конкурс ярдәме күрсәтүнең нәтиҗәле системасын булдыру |
| 6 | Яшьләр арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлтелгән семинарлар, киңәшмәләр, түгәрәк өстәлләр, башка иҗтимагый чаралар үткәрү | 2025 – 2027 | Сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга юнәлтелгән чараларга җәлеп ителгән яшьләр санын арттыру |
| 7 | Физкультура-спорт һәм сәламәтләндерү эшчәнлеге өлкәсендә чаралар үткәрү, сәламәт яшәү рәвеше алып баручы яшьләрнең уңай образын тудыру | 2025 – 2027 | Системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче яшьләр өлешен арттыру |
| 8 | Социаль булмаган күренешләрне профилактикалауга, милләтара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә һәм яшьләр арасында террорчылык идеологиясен таратуга каршы торуга юнәлтелгән чаралар үткәрү | 2025 – 2027 | Социаль булмаган күренешләрне профилактикалауга, милләтара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә һәм террорчылык идеологиясен таратуга каршы торуга юнәлтелгән чараларга җәлеп ителгән яшьләр санын арттыру |
| 9 | Яшьләргә районда һәм республикада гамәлгә ашырыла торган торак программалары турында мәгълүмат бирү | 2025 – 2027 | Яшьләрнең гамәлгә ашырыла торган дәүләт яшьләр сәясәте турында мәгълүматлылык дәрәҗәсе |
| 10 | Аерылышуларны профилактикалау, гаилә кыйммәтләрен, буыннар дәвамчанлыгын пропагандалау | 2025 – 2027 | Гаилә кыйммәтләрен популярлаштыру, аерылышулар саны кимү, демографик хәл |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | чаралары комплексын эшләү (профильле ведомстволар белән берлектә) | | яхшыру |
| 11 | Грант проектларында һәм конкурсларда катнашу | 2025 – 2027 | Грантлар язарга өйрәтелгән яшьләр өлешен арттыру. Гаризалар санын арттыру |
| 12 | Тукай муниципаль районы яшүсмерләренә һәм яшьләренә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү | 2025 – 2027 | Яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең психик сәламәтлеген саклау, шәхес үсешен төзәтү; Тукай муниципаль районы яшүсмерләренең һәм яшьләренең социаль адаптациясе |
| 13 | Төрле милек формасындагы предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм оешмаларда яшьләр хәрәкәтен үстерүгә ярдәм итү | 2025 – 2027 | Яшьләр инициативаларына ярдәм итү һәм эшләүче яшьләрнең потенциалыннан нәтиҗәле файдалану |